СОВЕТ БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18.08.2022 Баулы шәһәре №124

Баулы муниципаль районында
норматив хокукый актларга һәм
аларның проектларына коррупциягә
каршы экспертиза уздыру тәртибе
турындагы нигезләмәне раслау хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясы, «Татарстан Республикасында коррупциягә каршы көрәш турында» Татарстан Республикасы Законы, «Аерым норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 24 декабрендәге 883нче карары нигезендә, Баулы муниципаль районы Советы карар итте:

1. Кушымтадагы Баулы муниципаль районында норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы муниципаль районы Советының җирле үзидарә, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы

урынбасары, район Советы
Рәисе урынбасары Р.Г. Хәмидуллин

Баулы муниципаль районы
Советының 2022 елның __________
______ номерлы карарына
кушымта

Баулы муниципаль районында норматив хокукый актларга һәм аларның проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру тәртибе турындагы
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Коррупциягә каршы экспертиза муниципаль норматив хокукый актларда, аларның проектларында коррупция чагылышы өчен шартлар тудыруга ярдәм итә торган нигезләмәләр барлыкка килүен ачыклау (булдырмый калу) максатларында гамәлгә ашырыла.

2. Коррупциягә каршы экспертиза «Норматив хокукый актларның һәм норматив хокукый актлар проектларының коррупциягә каршы экспертизасы турында» 2009 елның 17 июлендәге 172-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 26 февралендәге 96 номерлы карары белән билгеләнгән методика нигезендә уздырыла.

3. Муниципаль норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза Баулы муниципаль районы башкарма комитетының юридик бүлеге тарафыннан гамәлдәге законнарга туры килү-килмәү мәсьәләсенә проект экспертизасы белән бер үк вакытта уздырыла.

Коррупциягә каршы экспертиза үз көчен югалткан яки бетерелгән норматив хокукый актларга карата үткәрелми.

4. Коррупциягә каршы экспертиза муниципаль норматив хокукый актларның һәм аларның проектларының коррупциягә каршы экспертизасын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән норматив хокукый актларга һәм норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза уздыру методикасы нигезендә уздырган өчен җаваплы вазыйфаи зат

тарафыннан үткәрелә һәм бәяләмәдә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча чагылдырыла.

Коррупциягә каршы экспертиза Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлегенә муниципаль норматив хокукый акт кергән вакыттан алып 10 көннән дә артык булмаган вакытта уздырыла.

5. Норматив хокукый актларда (норматив хокукый актлар проектларында) ачыкланган коррупциоген факторлар коррупциягә каршы экспертиза уздырганда төзелә торган бәяләмәдә чагыла. Бәяләмә рекомендация характерында була һәм тиешле орган, оешма яисә вазыйфаи зат тарафыннан мәҗбүри каралырга тиеш.

6. Коррупциягә каршы экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә норматив хокукый акт проектында ачыкланган коррупциоген факторлар күрсәтелергә тиеш (коррупциоген фактор ачыкланган норматив хокукый акт проектының тиешле структур берәмлекләрен күрсәтеп (бүлекләр, статьялар, өлешләр, пунктлар, пунктчалар, абзацлар).

7. Коррупциягә каршы экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмәдә шулай ук ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысуллары күрсәтелергә тиеш (норматив хокукый акт проектындагы кайбер нигезләмәләрне төшереп калдыру, норматив хокукый акт проектын тиешле үзгәрешләр белән тулыландыру, норматив хокукый акт проектының нормасын яңа редакциядә бәян итү).

8. Норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр мондый бәяләмә алынган көннән алып 30 көн эчендә проектны әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан һичшиксез каралырга тиеш.

9. Бәяләмәдә, экспертиза уздырганда ачыкланган, коррупция факторлары булмаган, әмма коррупция өчен шартлар тудырырга мөмкин нигезләмәләр дә күрсәтелә.

10. Проектны әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан коррупциягә каршы экспертиза уздырганда ачыкланган коррупциоген факторлар норматив хокукый акт проектын эшләп бетерү стадиясендә бетерелә.

Әзерләүче тарафыннан норматив хокукый акт проектына коррупциягә каршы экспертиза уздырганнан соң үзгәрешләр кертелгәндә норматив хокукый акт проекты кабат коррупциягә каршы экспертиза узарга тиеш.

11. Норматив хокукый актларга, норматив хокукый актлар проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза федераль законнар һәм Методика нигезендә Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан норматив хокукый актларга, норматив хокукый актлар проектларына бәйсез экспертиза уздыру буенча бәйсез экспертлар буларак аккредитацияләнгән юридик һәм физик затлар тарафыннан үткәрелә.

Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр булган норматив хокукый актлар проектларына яисә конфиденциаль характердагы белешмәләр булган норматив хокукый актлар проектларына карата үткәрелми.

12. Баулы муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары һәм норматив хокукый актлары проектларына коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру өчен, күрсәтелгән документларны әзерләүче аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Баулы муниципаль районы сайтында җирле үзидарә органнарына килештерүгә җибәрү көненә туры килгән эш көне эчендә урнаштыра, анда эксперт бәяләмәләре җибәрү өчен адрес (шул исәптән электрон почта адресы) һәм коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру нәтиҗәләре буенча бәяләмәләр кабул итә башлау һәм тәмамлану датасы турында мәгълүмат күрсәтелә.

Норматив актлар проектларына аларны әзерләүче билгеләгән коррупциягә каршы бәйсез экспертиза уздыру срогы аларны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырган көннән алып биш эш көненнән дә ким була алмый.

13. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы тарафыннан расланган формадагы бәяләмәдә күрсәтелә, ул рекомендация характерында булган һәм җирле үзидарә органнары тарафыннан аны алган көннән алып 15 көн эчендә һичшиксез каралырга тиеш.

Эксперт бәяләмәсе Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлегенә җибәрелә, ул алга таба әлеге нәтиҗәне документны эшләүчегә почта яисә курьер ысулы белән яисә электрон документ рәвешендә тапшыра.

Бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча, бәйсез экспертка, Баулы муниципаль районы башкарма комитетының юридик бүлеге утыз көн эчендә, ачыкланган коррупциоген факторларны бетерү ысулы турында тәкъдим булмаган очраклардан тыш, дәлилләнгән җавап җибәрелә.

14. Коррупциягә каршы бәйсез экспертиза, шулай ук Баулы муниципаль районы башкарма комитетының юридик бүлеге уздыра торган коррупциягә каршы экспертиза уздырганда ачыкланган коррупция өчен шартлар тудыруга ярдәм итә торган нигезләмәләр документларны әзерләүче тарафыннан юкка чыгарыла.

15. Документлар әзерләүче коррупциягә каршы бәйсез экспертиза нәтиҗәләре белән риза булмаган очракта, норматив хокукый актларда һәм аларның проектларында коррупция чагылышы өчен шартлар тудыруга ярдәм итә торган нигезләмәләр барлыгы турында таныклый торган документлар әзерләүче күрсәтелгән документларны һәм үзенең ризасызлыгы нигезләре турында аңлатма язуын Баулы муниципаль районы башкарма комитетының юридик бүлеге башлыгына карауга кертә.

16. Прокурорның таләпләре һәм коррупциягә каршы экспертиза нәтиҗәләре буенча бәяләмә законнарда билгеләнгән тәртиптә карала.